РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«17» апрель 2020 ел Олы Кайбыч авылы № 228

2019 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты үтәлеше хисабын раслау турында

2019 елда район бюджеты үтәлеше нәтиҗәләрен караганнан соң, Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 ел өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 502 403 106,36 сум, чыгымнар буенча 501 995 063,31 сум, керемнәрдән 408 043,05 сумга артыграк (бюджет профициты) дип һәм түбәндәге күрсәткечләрне расларга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты керемнәре әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә ;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетының ведомство структурасы буенча чыгымнары әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетының максатчан статьялары (Кайбыч муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре буенча чыгымнары әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин